ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 214 от «05» 06 2020 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
2016 нчы елның 19 нчы августында кабул
ителгән 1029 нчы номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы карары, «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 елның 10 ноябрендәге 480 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Мамадыш муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы эшчәнлеген алга таба камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 19 августындагы 1029 номерлы карары белән расланган Мамадыш муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы звеносы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- объект дәрәҗәсендә - гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссияләр вәкаләтләренә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, шул исәптән су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре керә.";

1.2. 1 нче кушымтаның 2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтенә кергән башкарма хакимиятнең федераль органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның идарә органнарын,көчләрен һәм чараларын берләштерә, шул исәптән су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча да, һәм ул

0000010494

"Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" Федераль законда каралган бурычларны үтәү максатларында үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов